Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

05.10.2022 № 25

ТР Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 9 номерлы карары белән расланган "Мәрхүмне күмү өчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. ТР Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 9 номерлы карары белән расланган "мәрхүмне күмү өчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент кертергә:
1.1. Регламентның 17 пунктын түбәндәге эчтәлекле өченче абзац белән тулыландырырга:

«Электрон образлары элек «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь чыганакта бирү, мондый документларга тамга салу йә аларны алу муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торса, һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Чәчәкле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Р. Фаисханов